**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № ________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарын урып-җыю чорына әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыруга кызыксындыру, үсемлекчелек тармагын үстерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарының урып-җыюга әзерлеге турында нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

2. Комиссия составын (2 нче кушымта) расларга.

3. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең көзге урып-җыю сезонына әзерлек турындагы нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 28 июлендәге ПР-160 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында:http://aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче урынбасары Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
____________ №____
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарын урып-җыю чорына әзерләү турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарының урып-җыюга әзерлеге турында нигезләмә урып-җыю кампаниясендә катнашучы хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын, хезмәт нәтиҗәлелеген арттыру, һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында эшләнде.

Комбайнчыларның экипажларын бүләкләү Актаныш муниципаль районы бюджеты хисабына башкарыла.

2.Комбайннарны карау һәм комбайнчылар экипажларын бүләкләү тәртибе.

Карау ел саен район зоналары буенча уздырыла:

1. Беренче зона - Богады-Сәфәр-Байсар-Чишмә юл чаты.
2. Икенче зона - Байсар МТП
3. Өченче зона - Сәфәр-Яхшый юл чаты
4. Дүртенче зона - Пучы (амбар) авылы кыры
5. Бишенче зона - Әтәс авылы (МТП)
6. Алтынчы зона - Чалманарат авылы (МТП)
7. Җиденче зона - Уразай авылы кырында
8. Сигезенче зона - Аэропорт кыры

Комбайннарның көзге урып-җыю сезонына әзерлеген карау түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

- комбайнны 2022 елгы уңышны җыю сезонына әзерләү;
- комбайнны эшкә әзерләү һәм эш процессы
- эш барышында техника иминлеген белү
- һөнәри сыйфатлар.

3. Җиңүчеләрне бүләкләү Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Башкарма комитеты раслаган комиссия карары нигезендә башкарыла.

3.1 Җиңүчеләрне бүләкләү комиссия карары буенча бер экипажга 2000 сум күләмендә башкарыла.

4. Караудa 88 экипаж катнаша. Комбайнчыларның исемлеге бирелә.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
____________ №____
2 нче кушымта

Комиссия составы

Комиссия рәисе:
Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Зарипов Л.Р.

Комиссия әгъзалары:
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Сәлимгәрәев Н.А.
ФЭБ башлыгы Мөхәммәтдинов Д.З.
ПО башлыгы Мөхәмәдиев Р.Р.
Россия авыл хуҗалыгы үзәге ФДУ Актаныш филиалы башлыгы Сәрвәров А.А.
Дәүләт техник күзәтчелегенең Актаныш филиалы башлыгы Хәкимов И.М.
Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык секторы мөдире Шаехова И.М.